Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Смыловка торак пунктында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 4 ноябрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56, 131-ФЗ номерлы Федераль законның, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Смыловка, Сухарево авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Смыловка Сухарево авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда гражданнарның үзара салымы чараларын 1000 сум күләмендә кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хатыннары керә. 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар күрсәтелгән сумманың 50%ы күләмендә түләнә.

2. Халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзүгә, ремонтлауга һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерүгә акчалар җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сухрау авыл җирлеге Р.Р.Галимов